**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Кышлау торак пунктында**

**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

“15” ноябрь 2023 ел.

№ 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлегенең Кышлау торак пунктында халык җыены

**КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Кышлау авыл җирлеге Кышлау авылы территорисендә, 2024 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Кышлау авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, тавыш бирү хокукына ия булган кешегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, 1 нче төркем инвалидлардан, мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, Россия Федерациясе оборона министрлыгы белән контракт төзегән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

1) Кышлау авылы территориясен чистарту (үлән чабу);
2) урам утларына хезмәт күрсәтү өчен түләү;
3) Кышлау авылындагы куперне ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча хезмәт хакы түләү).
4) янгынны сүндерү өчен махсуслаштырылган цистерна сатып алу.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлегенең Кышлау авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Кышлау авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4 Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Кышлау авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Кышлау авыл җирлеге башлыгы Кашшапов А.Х.